ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче Татар Чаллысы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«22» ноябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 ст., “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге карары нигезендә 2024 елның 22 ноябрендә “2025 елда Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыенында гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторга асылмалы җайланма сатып алу)

Гражданнар җыены беркетмәсенә ярашлы, җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 241 граждан кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 136 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: ”Риза” - 136 кеше, “каршы” – 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, махсус хәрби

операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән түләүне 50% ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау каралды һәм карар кабул ителде:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторга асылмалы җайланма сатып алу)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.